**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Г.Р. Державин исемендәге республика премиясен гамәлгә кую турында**

Татарстан Республикасының интеллектуаль һәм рухи потенциалын үстерү, әдәби иҗатка һәм юриспруденция өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә ярдәм күрсәтү, шулай ук Гавриил Романович Державин истәлеген мәңгеләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Г.Р. Державин исемендәге республика премиясен гамәлгә куярга.

2. Ел саен Г.Р. Державин исемендәге һәрберсе ике йөз мең сум күләмендә ике республика премиясе бирелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Г.Р. Державин исемендәге республика премиясе турындагы нигезләмәне эшләргә һәм расларга, шулай ук әлеге Указның үтәлешен тәэмин итүче башка чаралар күрергә.

4. «Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлеген раслау турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-651 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-913 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1014 номерлы һәм 2014 елның 7 ноябрендәге ПУ-1019 номерлы указалары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«8. Г.Р. Державин исемендәге республика премиясе.».

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 14 март
№ ПУ-240

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ